# Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләрне кабатлау һәм ныгыту

1) Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан ничә төре бар?

а) 12;

б) 2

2) Иярчен җөмләләрнең төзелеше ягыннан ничә төре бар?

а) 2;

б) 6;

3) Аналитик бәйләүче чараларга нәрсәләр керә?

а) көттерү паузасы, ияртүче теркәгечләр, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр;

б) көттерү паузасы, ияртүче теркәгечләр, ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр.

4) Синтетик бәйләүче чаралар:

а) кушымчалар, янәшә тору, парлы мөнәсәбәтле сүзләр;

б) кушымчалар, янәшә тору, бәйлек һәм бәйлек сүзләр.

5) ***Шулай, шулай булса да, шуңа*** нинди сүзләр?

а) ияртүче теркәгечләр;

б) ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр;

6) “Кич җиткәч, машиналарның соңгысын тутырдылар” җөмләсенә кайсы характеристика туры килә?

а) синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә;

б) аналитик иярчен урын җөмләле кушма җөмлә.

7) “Тукмагың кайда булса, сукмагың шунда булыр” җөмләсенә кайсы характеристика туры килә?

а) синтетик иярчен вакыт җөмләле кушма җөмлә;

б) аналитик иярчен урын җөмләле кушма җөмлә;

**ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН -**
(встать - сесть) “бас – утыр”

# Җаваплар:

1-а, 2-а, 3-б, 4-б, 5-б, 6-б, 7-б

# ЭЙ АР ГАЙД (“Руководство предположения/реакции”)

| Күнегү эшләгәнче + яки - | Сорау биремнәр | Күнегүне эшләп бетергәч + яки - |
|---|---|---|
| | Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша белдерә. | |
| | Иярчен урын җөмләбаш җөмләдәге эш яки хәлнең урынын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша ачыклый. | |
| | Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләр баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр, көттерү паузасы, ике нокта белән бәйләнә. | |
| | Ялгызак мөнәсәбәтле сүз булган баш җөмлә аналитик иярчен җөмләдән соң килсә, аның алдына өтер куела | |
| | Сугыш булган җирдә сагыш бар.<br>(-дә) [...] – синтетик иярчен урын җөмлә. | |
| | Иярчен урын җөмлә күбрәк – синтетик, сирәгрәк аналитик була. | |
| | Сугыш беткәч, батырлар күбәер.<br>[кем], (шул)- А., иярчен ия җөмлә | |

**ФИНК – РАЙТ- РАУНД – РОБИН** (подумай – запиши – обсуди в команде) – “ уйла – яз – командада тикшер”

# **ЭЙ АР ГАЙД** (“Руководство предположения/реакции”)

| Дәре башында + яки - | Сорау биремнәр | Дәрес ахырында + яки - |
|---|---|---|
| + | Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша белдерә. | + |
| + | Иярчен урын җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең урынын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша ачыклый. | + |
| + | Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләр баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгечләр, көттерү паузасы, ике нокта белән бәйләнә. | – |
| + | Ялгызак мөнәсәбәтле сүз булган баш җөмлә аналитик иярчен җөмләдән соң килсә, аның алдына өтер куела | + |
| + | Сугыш булган җирдә сагыш бар.<br>(-дә) [...] – синтетик иярчен урын җөмлә. | + |
| + | Иярчен урын җөмлә күбрәк – синтетик, сирәгрәк аналитик була. | - |
| – | Сугыш беткәч, батырлар күбәер.<br>(-кәч),[...] - аналитик иярчен вакыт җөмлә | - |

**МОДЕЛЬ ФРЕЙЕР** (помогающая учащимся глубоко понять и осознать изучаемые понятия и концепции) – теманың төрле якларын карала, аның төп һәм төп булмаган билгеләре, мисаллар һәм мисал була алмый торган очраклары языла

**КОНТИНИУС РАУНД РОБИН** – (продолжительный раунд робин) билгеле бер вакыт эчендә төркемдәге һәр укучы үзенең фикерен әйтеп сөйләшә

# Иярчен вакыт җөмләнең төп билгеләре

1. Иярчен вакыт җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша белдерә
2. Иярчен вакыт җөмләнең аналитик төрләре дә, синтетик төрләре дә бар.
3. Иярчен вакыт җөмлә кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? сорауларына җавап бирә.

# Иярчен урын җөмләнең төп билгеләре

1. Иярчен урын җөмлә баш җөмләдәге эш яки хәлнең урынын я турыдан – туры, я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз аша белдерә
2. Иярчен урын җөмлә күбрәк аналитик, сирәгрәк синтетик була.
3. Иярчен урын җөмлә кайда? кайдан? кая? сорауларына җавап бирә.

# Парковка